**Республики Татарстан Камско Тамагы  муниципаль районы**
**Советы Карары**

**20 мая  2019 ел** **№  207**

**2017 елның 10 ноябрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 111 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

2001 елның 21декабрендәге 178-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»”гы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законнар нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2017 елның 10 ноябрендәге 111 номерлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.3. Дәүләт яки муниципаль мөлкәт бәясе турындагы тәкъдимнәр аукционда катнашучылар тарафыннан сатуларны үткәрү барышында ачык күрсәтелә. Бер генә катнашучы катнашкан Аукцион хәл ителмәгән дип таныла.”;

Нигезләмәнең 5.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.5. Аукцион уздырганда мәгълүмат хәбәрендә, 4.5 пунктында күрсәтелгән мәгълүматлардан тыш. әлеге Нигезләмә башлангыч бәяне арттыру (“аукцион адымы”) күләме күрсәтелә.”;

Нигезләмәнең 5.8 пунктында “язма рәвештә хәбәр итү юлы белән” сүзләрен төшереп калдырырга;

5.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.9. Бер зат бер генә гариза бирергә хокуклы.”;

5.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.10. Аукционда катнашучыны җиңүче дип тану турында хәбәрнамә аукцион йомгаклары уздырылган көнне җиңүчегә җибәрелә.”;

6.5 пунктының беренче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

6.9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“6.9. Җиңүче тарафыннан сатуда катнашучыны халык алдында тәкъдим белән тану турында хәбәрнамә, сатуларга йомгак ясау көнендә, халыкка тәкъдим итү юлы белән, җиңүчегә җибәрелә.”;

7.2 пунктының 2 абзацының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Муниципаль милекне сатып алу турындагы тәкъдимнәр сатуларны үткәрү барышында претендентлар тарафыннан ачык күрсәтелә.”.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге Карар 2019 елның 1 июненнән үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Башлыгы, Кама Тамагы муниципаль**
**районы Советы рәисе** **Н.А. Вазыйхов**